| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь, 2025 ел Кошман ав. № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 28 ноябренә 11 сәг 00 минутка Кошман авылы, Тукай ур., 16 йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2025 елның 28 ноябренә 13 сәг 00 минутка Кошман авылы, Сәгыйди ур., 58 йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2025 елның 29 ноябренә 12 сәг 00 минутка Кошман авылы, Үзәк ур., 16 йорт адресы буенча урнашкан Кошман авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. 2025 елның 01 декабренә 10 сәг 00 минутка Кошман авылы, Үзәк ур., 16 йорт адресы буенча урнашкан Кошман авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. 2025 елның 01 декабренә 14 сәг 00 минутка Кошман авылы, Мәктәп ур., 31 йорт адресы буенча урнашкан Кошман төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.

6. 2025 елның 01 декабренә 15 сәг 00 минутка Кошман авылы, Мәктәп ур., 39 йорт адресы буенча урнашкан Кошман балалар бакчасы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын билгеләргә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслрга:

«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кошман авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ».

8. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Башлыгының 2025 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» Карарын юкка чыгарырга;

9.Әлеге карарны Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

10.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина